ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«20» «декабрь» 2021 ел** **№ 2256**

**2022 елда Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында**

«2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү дәүләт программасын раслау турында» 2009 елның 5 мартындагы 158 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 1023 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән һәм балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балалар, яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру, 2022 елда мәктәптә каникуллар чорында аларның мәшгульлеген тәэмин итү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Кушымта нигезендә түбәндәгеләрне расларга:
- «2022 елга Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру» муниципаль программасын (1 нче кушымта);
- Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, савыктыруны оештыру тәртибен (2 нче кушымта);
- Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, савыктыруны оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе (алга таба-район ведомствоара комиссиясе) турында нигезләмәне (3 нче кушымта);
- район ведомствоара комиссиясе составын (4 нче кушымта).

2. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә районның урта һәм төп мәктәпләре базасында мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре белән берлектә көндезге мәктәпкәчә савыктыру лагерьлары оештырырга, аларда ял итү өчен шартлар тудырырга, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчаларын, ата-аналар акчаларын җәлеп итәргә.

3. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә лагерьларны вакытында кадрлар белән тәэмин итәргә, походлар һәм экскурсияләр

вакытында балаларның сәламәтлеген һәм иминлеген саклауга аерым игътибар бирергә.

4. Көндезге мәктәпкәчә лагерьларны финанслау республика бюджеты акчалары исәбеннән 3133,5 мең сум, шул исәптән җәйге лагерьларны 2747,3 мең сум һәм кышкы лагерьларны 386,2 мең сум күләмендә тәэмин итәргә. Шулай ук җирле бюджет хисабына 31,6 мең сум күләмендә, шул исәптән җәйге - 27,7 мең сум, кышкы - 3,9 мең сум күләмендә финанслауны тәэмин итәргә

5.Җәйге чорда эшли торган мәктәп яны лагерьларында сменаның дәвамлылыгын 21 көн билгеләргә, ата-аналар акчасы-489,7 мең сум; кышкы чорда-7 көн, ата – аналар акчасы- 68,6 мең сум.

6. Түбәндәгеләрне оештырырга:

- Арчаның 6 нчы урта мәктәбе базасында 20 кешегә исәпләнгән «Азимут» район чатыр лагере. Лагерьны финанслауны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 124,5 мең сум, җирле бюджет акчалары исәбеннән 1,2 мең сум һәм ата-аналар акчалары исәбеннән 22,2 мең сум күләмендә гамәлгә ашырырга;

- районның алты гомуми белем бирү мәктәбе базасында 200 кешегә көндезге ял һәм хезмәт лагерьлары. Лагерьларны финанслауны Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән 667,4 мең сум һәм җирле бюджет исәбеннән 6,8 мең сум күләмендә гамәлгә ашырырга.

7. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә түбәндәгеләрне оештырырга:

- Арчаның 6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе базасында 20 кешегә исәпләнгән «Азимут» район чатыр лагере; 150 кешегә исәпләнгән «Шатлык» стационар балалар сәламәтләндерү лагере базаларында балалар һәм яшьләрнең закон нигезендә үткәрелә торган ялын һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы балалары ялын;

-физкультура-сәламәтләндерү чаралары;

- яшүсмерләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүгә юнәлтелгән чаралар.

8. 50 кешедән торган муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шатлык» стационар балалар сәламәтләндерү лагерена җибәрергә. Лагерьга баруны оештыру өчен 655,3 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын, 6,6 мең сум күләмендә җирле бюджет чараларын һәм 116,8 мең сум күләмендә ата-аналар акчаларын карарга.

9. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шатлык» стационар балалар сәламәтләндерү лагереның профильле сменаларына республика, Бөтенроссия олимпиадалары, конкурсларда һәм ярышларда җиңүчеләрне, иҗади сәләтле балалар, балалар хәрәкәте активистларын (2 сменада 50шәр кеше) җибәрергә. Лагерьга баруны оештыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын 1028,9 мең сум, җирле бюджет акчаларын - 10,3 мең сум һәм ата-аналар акчаларын 183,3 мең сум күләмендә карарга.

10. Авыр тормыш хәлендә калган балаларны стационар сәламәтләндерү лагерьларына җибәрергә. Сәфәрне оештыру өчен Татарстан Республикасы

бюджеты акчаларын - 383,1 мең сум, җирле бюджет акчаларын 3,9 мең сум күләмендә каларга.

11. Балаларның ялын оештырганда түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

-беренче чиратта ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, инвалид балалар, аз тәэмин ителгән, күпбалалы һәм тулы булмаган гаиләләрдәге балалар, качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләре балалары, кораллы конфликтларда зыян күргән хәрби хезмәткәрләр балалары ялын, савыктыруны, мәшгульлеген оештырырга;

- каникуллар чорында балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча өстәмә чаралар күрергә;

- оештырылган ял, сәламәтләндерү һәм эш белән күбрәк сандагы социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларның тәэмин итү өчен шартлар тудырырга;

- балалар ял итә торган учреждениеләрне яңа әзерләнгән азык-төлек, җиләк-җимеш продукциясе, дару препаратлары, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясе шартларында витаминнар, антисептиклар һәм шәхси иминлек чаралары, медицина җиһазлары, һаваны зарарсызландыру приборлары һәм янгынга каршы чаралар белән тәэмин итәргә;

- хокук тәртибен тәэмин иткәндә һәм сәламәтләндерү учреждениеләрен саклаганда хосусый сак предприятиеләрен җәлеп итәргә;

- Татарстан Республикасы бюджетыннан тукланугa, дератизациягә, антисептиклар, битлекләр, перчаткалар белән тәэмин итүгә акча каралга. Ата-аналарның акчалата кертемнәрен канцелярия һәм хуҗалык товарлары белән тәэмин итүгә җибәрергә.

12. Хезмәткәрләр өчен битлек режимын, балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген, хокук тәртибен, санитар-экологик һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлтелгән барлык катнашучыларның көндәлек термометриясен үтәп, санитар-эпидемиологик чаралар комплексын эшләргә һәм үткәрергә.

13. Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Арча, Биектау, Әтнә, Балтач районнарындагы территориаль бүлеге хезмәтләренең тиешле рөхсәтеннән башка барлык типтагы савыктыру лагерьлары ачылуга юл куймаска.

13. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

а) «Арча үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә:

- сәламәтләндерү учреждениеләрен медицина кадрлары белән тәэмин итәргә;

- балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә җибәрелә торган персоналны укудан һәм каникулдан буш вакытта эшкә урнаштырганда, балигъ булмаганнарга медицина тикшерүләрен оештыруны тәэмин итәргә;

б) Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районындагы бүлегенә балаларны ташуның иминлеген һәм районның сәламәтләндерү учреждениеләрендә хокук тәртибен тәэмин итәргә;

в) Арча шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына 2022елның 10 апреленә кадәр үзләренең утырышларында җәйге ял турындагы мәсьәлә буенча фикер алышырга, конкрет чаралар эшләргә һәм расларга.

14. Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә:

- балалар һәм яшүсмерләр белән спорт һәм ял эшләрен оештыру өчен спорт залларының, стадионнарның, яшәү урыны буенча мәйданчыкларның эшен тәэмин итәргә;

-туристик-экскурсия эшен активлаштырырга.

15.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

16. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.12.2021 ел, № 2256
карарына 1 нче кушымта

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

Татарстан Республикасы Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия рәисе урынбасары, ТР яшьләр эшләре министры
______________________Т.Д. Сөләйманов
"___" ______________ 2021 ел

РАСЛЫЙМ:
Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе
________________Р.Р. Мөхәрәмов
"____"___________ 2021 ел

# «2022 ЕЛДА АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА БАЛАЛАРНЫҢ ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУ» ПРОГРАММАСЫ

## 1. Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа исеме | "2022 елда Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру" (алга таба-Программа) |
| Программаның муниципаль заказчысы | АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| Программаның төп эшләүче | Арча муниципаль районы башкарма комитеты "Мәгариф идарәсе" муниципаль учреждениесе |
| Программаның максатлары | Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле шартлар тудыру. |
| Программаның бурычлары | Балалар һәм яшьләрнең, балалар һәм яшьләр туризмы һәм спортның төрле ял, сәламәтләндерү һәм мәшгульлекләрен үстерү;<br>сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне ачыклау, аларга ярдәм итү системасын формалаштыру;<br>балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмаларына, волонтерларга, ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү;<br>балалар авыруын һәм инвалидлыкны профилактикалау;<br>балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;<br>авыр тормыш хәлендә булган балаларны җәмгыятькә нәтиҗәле комплекслы социаль яклануны һәм интеграцияләүне формалаштыру; |

| | |
|---|---|
| Программаның төп башкаручылары | Арча муниципаль районы башкарма комитеты;<br>Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары;<br>Татарстан Республикасы дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм төбәкара элемтәләр агентлыгы (килешү буенча);<br>Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" муниципаль учреждениесе;<br>ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>"Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча);<br>"Арча РҮХ" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча);<br>Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе;<br>Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>Арча районының дәүләт янгын күзәтчелеге органы (килешү буенча);<br>Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Арча, Биектау, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлеге (килешү буенча). |
| ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОГЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ | 2022 ел |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Иҗади яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен стационар һәм чатыр лагерьларында профильле сменалар оештыру.<br>2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял лагерьларында сменалар оештыру.<br>3. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру.<br>4. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында сменалар оештыру. |

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 2021 елга 6934,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга, аларны савыктыруга субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан 5992,9 мең сум; җирле бюджет акчалары - 60,6 мең сум; ата-аналар акчалары - 880,6 мең сум |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Чараларны тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:<br>1550гә кадәр кешене оешкан төстәге ял итү формалары белән колачларга;<br>балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештырырга, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итәргә, сәламәтләндерү эффектын арттыру өчен кирәкле шартлар тудырырга. |

## 1 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАРЫН ТАСВИРЛАУ

Балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру халыкның социаль иминлегенең мөһим өлеше булып тора. Дәүләт хакимияте органнарына балаларның сәламәтлеген ныгыту өчен барлык мөмкинлекләрне кулланырга, каникуллар вакытын балаларның интеллектуаль, иҗади сәләтләрен үстерүгә, аларның социаль адаптациясенә юнәлтелгән эчтәлекле эшчәнлек белән тулыландырырга кирәк.

Хәзерге шартларда балаларның ялын һәм аларны савыктыру системасын үстерү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының төп юнәлешләренең берсе.

| Прблема исеме | Барлыкка килү сәбәпләрен анализлау, максатчанлыгын нигезләү һәм аны муниципаль дәрәҗәдә хәл итү зарурилыгы | Муниципаль программаның тиешле максаты исеме | Әлеге муниципаль программа ирешүгә ярдәм итә торган муниципаль заказчы бурычының атамасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Замана баласының сәламәтлеге торышының гомуми начараюы; | Күп кенә гаиләләрнең социаль-икътисади хәле каникуллар вакытында аларның ялын һәм савыктыруны | Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өчен тиешле шартлар тудыру, | Каникуллар вакытында балаларның ялын һәм савыктыру системасын саклау; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ял итү белән тәэмин итү проблемасы | мөстәкыйль оештырырга мөмкинлек бирми | каникуллар вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итү, савыктыруның нәтиҗәлелеген арттыру | каникуллар вакытында балаларның ялын тәэмин итү өчен шартлар тудыру, аларның физик, мәдәни потенциалын үстерү |

## 2 нче бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2022 ел

## 3 нче бүлек. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ТАСВИРЛАУ

1. Иҗади сәләтле яисә социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, авыр тормыш шартларында балалар өчен, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен стационар һәм палатка лагерьларында профильле сменалар оештыру.
2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял лагерьларында сменаларын оештыру.
3. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру.
4. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының хезмәт һәм ял лагерьларында сменаларын оештыру.

## 4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программалы чаралар үтәлешен районның балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру комиссиясе тикшереп тора. Әлеге комиссия программа чараларын төгәлләштерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертә һәм балаларның ялын һәм

сәламәтләндерүен оештыруга бүлеп бирелгән финанс чараларын бүлүне һәм куллануны тикшереп тора. Программа чараларын үтәү эзлеклелеге аларның өстенлеге һәм гамәлгә ашыру сроклары белән билгеләнә.

Чараларның барышы һәм нәтиҗәләре район комиссиясе утырышларында каралырга мөмкин.

Программаның заказчысы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, Программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларын исәпкә алып, Программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын ачыклый.

Программа чараларын үтәүчеләр Программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын һәм ресурсларны сыйфатлы һәм үз вакытында үтәү, рациональ файдалану өчен җаваплы.

Программаны гамәлгә ашыруның барышын Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тикшереп тора.

## 5 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА МАКСАТЛАРЫ ИНДИКАТОРЛАРЫ

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген ирешелгән нәтиҗәләр күрсәткечләре буенча бәяләргә мөмкин.

Программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- 1550гә якын кешене оештырылган ял итү формалары белән колачларга;
- балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өчен тиешле шартлар тудырырга, аларны каникуллар вакытында эш белән тәэмин итәргә, савыктыруның нәтиҗәлелеген күтәрергә.
- балалар ялының, савыктыруны һәм мәшгульлегенең яңа формаларын үстерергә.

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | 2022 төп ел күрсәткече | муниципаль программаны 2020 елда гамәлгә ашыру | программаны 2021 елда гамәлгә ашыру |
|---|---|---|---|---|
| Укучылар саны, барлыгы | кеше | 5842 | 5418 | 5601 |
| Ял иткән балалар саны, барлыгы | кеше | 1590 | 350 | 1400 |

## 6 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

Программаны гамәлгә ашыру балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга, аларны савыктыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан 5992,9 мең сум; җирле бюджет акчалары исәбеннән 60,6 мең сум, ата-аналар акчалары 880,6 мең сум исәбеннән гамәлгә ашырыла.
Программаны 2022 елга финанслауның гомуми күләме - 6934,1 мең сум.

| **Финанслау чыганаклары** | **2022 ел** |
|---|---|
| Барлыгы, шул исәптән: | 6934,1 |
| Республика бюджеты (85%) | 5992,9 |
| Җирле бюджет (1%) | 60,6 |
| Ата-ана акчалары (15 %) | 880,6 |

## 2. Әлеге программа кысаларында хезмәт күрсәтү күләмнәренең расланган нормативлары нигезендә үткәрелә торган чаралар

| Чаралар исеме | Үткәрү вакыты | Кеше саны | Оештыру өчен җаваплы (башкаручы) |
|---|---|---|---|
| Спортта казанышлары булган балалар өчен «Азимут» чатыр лагеренда профильле смена оештыру | Июнь | 20 | Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял лагерьларында сменаларны оештыру | июнь | 830 | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ |
| Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) сменалар оештыру | июнь-июль | 50 | Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге<br>Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Стационар лагерьларда профильле сменалар оештыру | Июль-август | 100 | Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге<br>Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ |
| Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында сменаларны оештыру | июнь-август | 200 | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ |
| Стационар һәм палата лагерьларында авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын оештыру | июнь-август | 40 | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ |

### 3. Иҗади сәләтле яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен палаткалы лагерьларда профильле сменалар оештыру

| Палаткалы лагерь (оештыручы) исеме | Үткәрү территориясе | Кеше саны | Көн саны | Юлламаның норматив бәясе, мең сум | ТР бюджетыннан субсидияләр, мең сум | Ата-аналар кертеме**, мең сум | Җирле бю мең сум джет, |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Азимут» | Арча муниципаль районы | 20 | 7 | 148,0 | 124,5 | 22,2 | 1.2 |

### 4. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә көндезге дагерьларда укучылар сменаларын оештыру

| База (мәктәп) оешмасы өчен | Үткәрү территориясе | Кеше саны | Көн саны | Юлламаның норматив бәясе, мең сум | ТР бюджетыннан субсидияләр, мең сум | Ата-аналар кертеме, мең сум | Җирле бюджет, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Арчаның 1нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 90 | 21 | 3933,3 | 297,9 | 53,1 | 3,0 |
| "Арчаның 3нче урта | Арча | 50 | 21 | 3933,3 | 165,5 | 29,5 | 1,6 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гомуми белем бирү мәктәбе» | шәһәре | | | | | | |
| Арчаның 5нче гимназиясе | Арча шәһәре | 75 | 21 | 3933,3 | 248,3 | 44,2 | 2,5 |
| "Арчаның 6 урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 90 | 21 | 3933,3 | 297,9 | 53,1 | 3,0 |
| "Арчаның 7нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 35 | 21 | 3933,3 | 115,8 | 20,7 | 1,2 |
| "Апаз урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Апаз авылы | 35 | 21 | 3933,3 | 115,8 | 20,7 | 1,2 |
| "Ашытбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Ашытбаш авылы | 35 | 21 | 3933,3 | 115,8 | 20,7 | 1,2 |
| "Лесхоз урта гомуми белем бирү мәктәбе» | бистәсе Үрнәк | 45 | 21 | 3933,3 | 149,0 | 26,5 | 1,5 |
| "Түбән Мәтәскә урта урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Түбән Мәтәскә авылы | 35 | 21 | 3933,3 | 115,8 | 20,7 | 1,2 |
| "Наласа урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Наласа авылы | 35 | 21 | 3933,3 | 115,8 | 20,7 | 1,2 |
| "Яңа Кенәр урта урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Яңа Кенәр авылы | 60 | 21 | 3933,3 | 198,6 | 35,4 | 2,0 |
| "Иске Чүриле урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Иске Чүриле авылы | 35 | 21 | 3933,3 | 115,8 | 20,7 | 1,2 |
| "Шушмабаш урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Шушмабаш авылы | 60 | 21 | 3933,3 | 198,6 | 35,4 | 2,0 |
| "Казанбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» | Казанбаш авылы | 25 | 21 | 3933,3 | 82,8 | 14,8 | 0,8 |
| "Кәче төп гомуми белем бирү мәктәбе» | Кәче авылы | 20 | 21 | 3933,3 | 66,2 | 11,8 | 0,6 |
| "Ташкичү төп гомуми белем бирү мәктәбе» | Ташкичү авылы | 15 | 21 | 3933,3 | 49,7 | 8,9 | 0,5 |
| "Хәсәншәех төп гомуми белем бирү мәктәбе» | Хәсәншәех авылы | 20 | 21 | 3933,3 | 66,2 | 11,4 | 0,6 |
| "Курса-Почмак гомуми урта белем бирү мәктәбе» | Курса-Почмак авылы | 35 | 21 | 3933,3 | 115,9 | 20,7 | 1,2 |
| "Яңа Кырлай урта урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Яңа Кырлай авылы | 35 | 21 | 3933,3 | 115,9 | 20,7 | 1,2 |
| **Барлыгы: 19** | | **830** | **21** | | **2747,3** | **489,7** | **3,9** |

| **Кышкы чорда** | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Арчаның 1нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 65 | 7 | 1310,5 | 71,7 | 12,7 | 0,7 |
| "Арчаның 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 70 | 7 | 1310,5 | 77,3 | 13,7 | 0,8 |
| "Арчаның 3нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 40 | 7 | 1310,5 | 44,1 | 7,9 | 0,4 |
| Арчаның 5нче гимназиясе | Арча шәһәре | 65 | 7 | 1310,5 | 71,7 | 12,7 | 0,7 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Арчаның 6 урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 70 | 7 | 1310,5 | 77,3 | 13,7 | 0,8 |
| "Шушмабаш урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Шушмабаш авылы | 40 | 7 | 1310,5 | 44,1 | 7,9 | 0,5 |
| **Барлыгы: 6** | | **350** | **7** | | **386,2** | **68,9** | **3,9** |

## 5. Стационар лагерьларда профильле сменалар оештыру

| Стационар ДОЛ исеме | Үткәрү территориясе | Баланс тотучы исеме | Кеше саны | Көн саны* | Юлламаның норматив бәясе, мең сум | Татарстан Республикасы бюджетыннан субси-дияләр, мең сум | Ата-ана кертеме, мең сум | Җирле бюджет, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Шатлык" ДОЛ | Арча муниципаль районы | "Мәгариф идарәсе" МУ | 50 | 18 | 778,8 | 655,3 | 116,8 | 6,6 |
| "Шатлык" ДОЛ | Арча муниципаль районы | "Мәгариф идарәсе" МУ | 50 | 7 | 302,8 | 254,8 | 45,4 | 2,5 |
| "Шатлык" ДОЛ | Арча муниципаль районы | "Мәгариф идарәсе" МУ | 50 | 21 | 919,8 | 774,1 | 137,9 | 7,8 |

## 6. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында сменаларын оештыру

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Кеше*саны | Көн*саны | Юлламаның норматив бәясе (сум) | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-аналар кертеме, сум | Җирле бюджет, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Җәйге чорда** | | | | | | | |
| "Арчаның 1нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 30 | 18 | 3257,5 | 100,1 | 0 | 1,0 |
| "Арчаның 6 урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 30 | 18 | 3257,5 | 100,1 | 0 | 1,0 |
| "Яңа Кенәр урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Арча шәһәре | 25 | 18 | 3257,5 | 83,4 | 0 | 0,9 |
| Арчаның 5нче гимназиясе | Арча шәһәре | 30 | 18 | 3257,5 | 100,1 | 0 | 1,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Арчаның 7нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Айван авылы | 20 | 18 | 3257,5 | 66,8 | 0 | 0,7 |
| "Шушмабаш урта гомуми белем бирү мәктәбе» | Шушмабаш авылы | 65 | 18 | 3371,5 | 216,9 | 0 | 2,2 |
| **Барлыгы:6** | | **200** | **18** | | **667,4** | **-** | **6,8** |

## 7. Авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын оештыру

| **Кеше саны** | **Көн саны*** | **Юлламаның норматив бәясе ( сум)** | **ТР бюджетыннан субсидияләр (сум)** | **Ата-ана-кертеме (сум)** | **Җирле бюджет, (сум)** |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | 7 | 111 | 109,8 | 0 | 1,1 |
| 10 | 21 | 184 | 182,1 | 0 | 1,8 |
| 15 | 7 | 920 | 91,8 | 0 | 0,9 |

## 8. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан балалар һәм яшьләрнең ялын һәм савыктыруны оештыруга субсидияләр

| **Күрсәткеч атамасы** | **Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидияләр суммасы** |
|---|---|
| Муниципаль районның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары арасыннан бер балага Татарстан Республикасында балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга финанс чыгымнары нормативы (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) | 2,6 мең сум |

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.12.2024 ел, №2256
карарына 2 нче кушымта

# Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру тәртибе

## 1. Көндезге лагерьда (мәктәп яны лагерьлары) балаларның ял сменасын оештыру

1.1. Көндезге лагерьга (мәктәп яны) ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризалары нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары җибәрелә.

1.2. Ата-аналар гаризасы кушымтада бирелгән форма буенча укучы белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесенә тапшырыла.

1.3. Гомуми белем бирү учреждениесе ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаризалар нигезендә көндезге (мәктәп яны) лагерьларга җибәрелә торган гомуми белем бирү учреждениесе балалары исемлеген формалаштыра һәм аны муниципаль район башкарма комитетына тапшыра. Исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән әти-әнисенең (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган датасы, ае, елы, җенесе;

ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыны;

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме;

бала укый торган сыйныф.

Муниципаль район башкарма комитеты гомуми белем бирү учреждениеләре балалары исемлекләре нигезендә муниципаль район балаларының җыелма исемлеген һәм көндезге лагерьларда (мәктәп яны) аларның ялын оештыру планын төзи.

1.4. Көндезге (мәктәп яны) лагерьларда балаларның ялын оештыру планы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган муниципаль райондагы көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә төзелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

көндезге лагерьлар оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләре исемнәре (мәктәп яны лагерьлары);

гомуми белем бирү учреждениеләре киселешендә көндезге (мәктәп яны) лагерьларында оештырылган урыннар саны;

гомуми белем бирү учреждениеләре киселешендә көндезге лагерьларда сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

балаларны алар базасында көндезге лагерьлар (мәктәп яны) һәм сменалар оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләре буенча бүлү.

1.5. Көндезге (мәктәп яны) лагерьларда балаларның ялын оештыру планы муниципаль район башкарма комитеты карары белән сәламәтләндерү кампаниясе чорына раслана.

1.6. Өч көн эчендә муниципаль район башкарма комитеты Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына сәламәтләндерү учреждениеләренә килгән балалар саны турында мәгълүмат җибәрә.

1.7. Ай саен, 25 числога кадәр, муниципаль район башкарма комитеты, ял иткән балалар саны һәм аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга бүлеп бирелгән акчаны күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына сәламәтләндерү кампаниясе мониторингын җибәрә.

1.8. Көндезге (мәктәп яны) лагерьларда сәламәтләндерү кампаниясе тәмамланганнан соң җиде көн эчендә муниципаль район башкарма комитеты Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына көндезге лагерьларда (мәктәп яны) эшләнгән эшләр турында хисап җибәрә.

## 2. Стационар лагерьларда муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының ялын һәм савыктыруны оештыру

2.1. Ата-аналарының (законлы вәкилләренең) берсе муниципаль яки дәүләт учреждениесе хезмәткәре булган гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары ата-ана (законлы вәкил) эшләүче муниципаль яки дәүләт учреждениесенең вәкиллекле органына тапшырылган гаризасы нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә. Ата-аналар гаризасы кушымтада бирелгән форма буенча бирелә.

2.2. Муниципаль яки дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең вәкиллекле органы стационар лагерьларга җибәрелә торган учреждение хезмәткәрләре балаларының беренчел исемлеген төзи.

2.3. Беренчел исемлектә күрсәтелә:

Учреждение исеме;

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән әти-әнисенең (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

икенче ата-ананың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

икенче ата-ананың эш урыны (булганда);

баланың туган датасы, ае, елы, җенесе;

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме;

бала укый торган сыйныф.

2.4. Муниципаль район башкарма комитеты учреждениенең беренчел исемлеге нигезендә муниципаль яки дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең стационар лагерьларга җибәрелә торган балаларының якынча җыелма исемлеген төзи.

2.5. Муниципаль район башкарма комитеты балаларның җыелма исемлеге нигезендә стационар лагерьларда аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планын төзи. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

муниципаль бирем нигезендә муниципаль яки дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары җибәрелә торган муниципаль стационар лагерьларда урыннарның һәм сменаларның атамасы, саны;

стационар лагерьларга юлламалар саны.

2.6. Муниципаль яки дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балаларының ялын оештыру планы муниципаль район башкарма комитетының хокукый акты белән раслана.

2.7. Өч көн эчендә муниципаль район башкарма комитеты Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына сәламәтләндерү учреждениеләренә килгән балалар саны турында мәгълүмат җибәрә.

2.8. Ай саен, 25 числога кадәр, муниципаль район башкарма комитеты, ял иткән балалар саны һәм аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга бүлеп бирелгән акчалар күләме күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына сәламәтләндерү кампаниясе мониторингын җибәрә.

2.9. Стационар лагерьларда дәүләт хакимияте органнары, дәүләт органнары, муниципаль яки дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балаларын җәйге сәламәтләндерү кампаниясе тәмамланганнан соң, муниципаль район башкарма комитеты Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына дәүләт хакимияте органнары, дәүләт органнары, муниципаль яки дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балаларын җәйге сәламәтләндерү кампаниясе турында җиде көн эчендә стационар лагерьларда хисап җибәрә.

## 3. Авыр тормыш хәлендәге балаларның ялын һәм савыктыруны оештыру

3.1. Ата-аналарның берсе (законлы вәкилләр, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждение җитәкчеләре) гаризасы нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы сәламәтләндерү лагерьларына җибәрә:

җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләр, шул исәптән күпбалалы гаиләләр, тулы булмаган гаиләләр, ата-аналары пенсионерлар яки инвалид булган гаиләләр балаларын;

социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләр, шулай ук ведомствоара учетта торучы балаларны;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомствосындагы башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучы ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны;

азкеремле һәм аз тәэмин ителгән гаиләләрдәге балалар, шулай ук тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны;

шифаханәдә дәвалануга юллама өлешендә социаль хезмәт күрсәтүдән баш тартмаган үз-үзләренә хезмәт күрсәтүгә сәләтле булган инвалид балаларны.

3.2. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждение җитәкчеләренең) гаризасы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы сәламәтләндерү учреждениеләренә җибәрелә торган авыр тормыш хәлендә калган балаларның якынча исемлеген төзи һәм сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы утыз көн кала Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына әлеге беренчел исемлекне тапшыра.

3.4. Беренчел исемлектә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ата-ананың фамилиясе, исеме, атасының исеме (законлы вәкил, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешма җитәкчесе);

икенче ата-ананың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) эш урыны (булганда);

баланың туган датасы, ае, елы, җенесе;

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме;

балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждение исеме (балигъ булмаганнар өчен махсус учреждениеләр тәрбияләнүчеләре өчен);

авыр тормыш хәлендә булган баланың категориясе;

бала укый торган сыйныф күрсәтелә.

3.5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органының беренчел исемлеге нигезендә авыр тормыш хәлендә булган балаларның савыктыру учреждениеләренә җибәрелә торган җыелма исемлеген формалаштыра.

3.6. Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләр һәм социаль куркыныч хәлдә булган балалар сәламәтләндерү учреждениеләренә юлламалар алуга беренче чиратта хокуклы.

3.7. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органының күрсәтелгән исемлеге нигезендә авыр тормыш хәлендә булган балаларның стационар учреждениеләргә җибәрелүче балаларның җыелма исемлеген төзи.

3.8. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы авыр тормыш хәлендә булган балаларның җыелма исемлеге нигезендә стационар лагерьларда аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планын төзи.

3.9. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планында авыр тормыш хәлендә калган балалар категорияләре һәм муниципаль районнар киселешендә стационар лагерьларда урыннар һәм сменаларның дәвамлылыгы булырга тиеш.

3.10. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры боерыгы белән раслана.

3.11. Ай саен, 25 числога кадәр, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы, ял иткән балалар саны һәм аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга бүлеп бирелгән акчалар күләме күрсәтеп, сәламәтләндерү кампаниясе мониторингын Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына җибәрә.

3.12. Җәйге сәламәтләндерү кампаниясе тәмамланганнан соң җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы адресына балаларны җәйге сәламәтләндерү кампаниясе турында хисап җибәрә.

## 4. Стационар (чатыр) лагерьлар, шул исәптән Кара диңгез ярында профильле сменаларда балаларның ялын һәм савыктыруны оештыру

4.1. Стационар (чатыр) лагерьларының профильле сменаларында, шул исәптән Кара диңгез буенда катнашу өчен Республика, Бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре, иҗади сәләтле яки социаль актив балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалар һәм яшьләр, Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен тормышка ашыру кысаларында балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр җибәрелә.

4.2. Гомуми белем бирү учреждениеләре, башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучылары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына (Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы) тапшырылган (алга таба - профильле сменаларны оештыручылар) бер ата-ананың (законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә стационар (палатка) лагерьларга җибәрелә.

4.3. Ата-аналар гаризасы профильле сменаларны оештыручылар тарафыннан расланган форма буенча бирелә, алар стационар (палаткалар) лагерьларына җибәрелә торган профильле сменада катнашучы балаларның җыелма исемлеген формалаштыралар.

4.4. Җыелма исемлектә профильле сменаның һәр катнашучысының:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

әти-әнисенең (законлы вәкилләрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) эш урыны;

баланың туган датасы, ае, елы, җенесе;

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме;

сменада катнашучы балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе, иҗтимагый оешма, иҗтимагый яшьләр оешмасы исеме (булганда);

баланың казанышлары яки иҗтимагый оешмалар яки берләшмәләр тәкъдимнәре исемлеге;

бала укый торган сыйныф;

дәүләт (муниципаль) заданиесе нигезендә профильле смена оештырылачак стационар (чатыр) лагерьның исеме яки ачык конкурс йомгаклары буенча стационар (палатка) лагерьларда балаларның ялын оештыруга юлламалар алу зарурлыгы турында сылтама күрсәтелә

4.5. Профильле сменаны оештыручы профильле сменаларда катнашучы балаларның җыелма исемлеге нигезендә стационар (чатыр) лагерьларның профильле сменаларында аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планын төзи.

4.6. Профильле сменаларда катнашучы балаларның ялын оештыру планы үз эченә ала:

дәүләт (муниципаль) заданиесе нигезендә профильле сменаларда катнашучы балалар җибәрелә торган дәүләт (муниципаль) стационар (палатка) лагерьларында урыннар һәм сменаларның атамасы, саны;

стационар лагерьларга юлламалар саны.

4.7. Профильле сменаларда катнашучы балаларның ялын оештыру планы профильле сменаларны оештыручының боеру документы белән раслана.

4.8. Профильле сменаларны оештыручылар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына сәламәтләндерү учреждениеләренә килгән балаларның саны турында өч көн эчендә мәгълүмат җибәрә.

4.9. Ай саен 25 числога кадәр, профильле сменаларны оештыручылар, аерым алганда, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм җирле үзидарә органнары ял иткән балалар саны һәм аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга бүлеп бирелгән акчалар күләмен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына сәламәтләндерү кампаниясенә мониторинг җибәрәләр.

4.10. Стационар лагерьларда оешма хезмәткәрләренең балаларын җәйге сәламәтләндерү кампаниясе тәмамланганнан соң җиде көн эчендә муниципаль район башкарма комитеты Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт

министрлыгы адресына стационар лагерьларда оешма хезмәткәрләренең балаларын җәйге сәламәтләндерү кампаниясе турында хисап җибәрә.

## 5. Хроник авырулары булган балаларның (шул исәптән ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) бер кеше озата бару нигезендә) ялын һәм савыктыруны оештыру

5.1. Хроник авырулары булган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе, шул исәптән бер ата-ананың (законлы вәкилне) аны озатып йөрүе бергә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итүһ әм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

5.2. Санаторий-курорт учреждениеләрендә сменалар оештырганда, хроник авырулары булган 4 яшьтән алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру рөхсәт ителә, шул исәптән бер ата-ананың (законлы вәкилнең) озатып йөрүе нигезендә.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____________ ел, №__
карарына 3 нче кушымта

## Балаларның һәм яшьләрнең ялын, савыктыруны, мәшгульлеген оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия (алга таба-Комиссия) балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру максатларында төзелде һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитетының координацияләүче органы булып тора.

2. Комиссияне ике урынбасары булган рәис җитәкли. Комиссия составына кызыксынучы ведомстволар һәм оешмалар вәкилләре керә.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга һәм әлеге нигезләмәгә таяна.

4. Комиссиянең төп бурычлары:

- ведомстволар, төрле фондлар, акционерлык җәмгыятьләре, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр һәм берләшмәләр, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм әзерләү буенча иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомстволар, оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау, аларның комиссия

утырышларында хисапларын тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм финанслау мәсьәләләрен карау;

- балалар һәм яшьләрнең ял итү программаларын тормышка ашыруны контрольдә тоту.

5. Комиссиянең хокуклары:

- Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының "Җәй" балалар һәм яшүсмерләрнең ялын, аларны савыктыруны, ялын һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча республика үзәге" дәүләт учреждениесе белән Арча муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру чараларын гамәлгә ашыру буенча төзелгән килешүләр кысаларында сменаларны оештыручыларны билгеләү;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитетына кертү;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы ведомстволардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән аның компетенциясенә караган документлар, белешмәләр, материаллар соратып алу;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үтәлешен контрольдә тоту.

6. Аның компетенциясе кысаларында кабул ителгән комиссия карарлары барлык ведомстволар, учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар тарафыннан аларның милек рәвешләренә бәйсез рәвештә үтәлергә тиеш.

7.Комиссия карарлары утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә һәм үтәлеше өчен мәҗбүри булып тора.

Утырыш беркетмәләре Комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.12.2021 ел, № 2256
карарына 4 нче кушымта

**Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм мәшгульлеген оештыру буенча район комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Вафина Э.Ш. | - Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Мөхәмәдияров Р.Д. | - Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Габделгазизов И.Н. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Ильина Л.Ю. | - «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгының тәрбия эшләре буенча урынбасары, комиссия секретаре (килешү буенча); |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Галимова С.П. | - «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы ФБП» МКУ җитәкчесе; |
| Баһавиев А.Р. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Арча районында бүлек башлыгы (килешү буенча); |
| Идрисов Р.И. | - «Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Салкова Э.В. | - Биектау районы буенча баш дәүләт санитар табиб урынбасары –башлык урынбасары (килешү буенча); |
| Әюпов И.И. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ башлыгы; |
| Хәкимҗанова А.Ф. | - Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре; |
| Шакирова М.Н. | - ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районындагы бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сафин Р. Р. | - Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча идарәсенең Арча муниципаль районы буенча ОНД башлыгы |
| Рәхматуллин Н.Р. | - дәүләт инспекциясенең өлкән белгече Татарстан Республикасында хезмәтне саклау буенча (килешү буенча) |

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының
«20» 12 20 21 ел, № 2256
карары белән расланган 2022 елда Арча муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, савыктыруны, мәшгульлеген оештыру тәртибенә кушымта

Балалар савыктыру лагере башлыгына
_______________________________________________
Ананың ф. и. а. и.
_______________________________________________
Эш урыны _________________________________
_______________________________________________
Атаның ф. и. а.и.
_______________________________________________
Эш урыны ________________________________________________
Баланың законлы вәкиленең
ф.и.а.и.______________________________________________
Индекс күрсәтелгән өй адресы (теркәлү урыны, яшәү урыны)
_______________________________________________
_______________________________________________
Элемтә өчен телефоннар :йорт, эш, сот.)
_______________________________________________

## Гариза

Балага______________________(фамилиясе, И. А. И. тулысынча) ___________________туган елы, ае, көне____________________җенесе ____, туу турында таныклык (паспорт) сериясе ____________ № ____________________ бирү датасы____________________________, бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме_________________________, белем алу сыйныфы_________, лагерьга________________________ сменага_____________ юллама бирүегезне сорыйм.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган ятим балалар, күп балалы гаиләләрдән, тулы булмаган гаиләләрдән, качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән, хәрби конфликтларда зыян күргән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләреннән, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә исәптә торучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән өстәмә мәгълүматлар (ассызыкларга кирәк).

**Гаризага теркәлә:**

*- баланың уку урыныннан белешмә,*

*- баланың туу турында таныклык күчермәсе яки паспорт күчермәсе,*

*- баланың спортта ирешкән уңышлары, спорт ярышларында, фән олимпиадаларында, иҗади фестивальләрдә, конкурсларда катнашуы турында мәктәп яки өстәмә белем бирү учреждениеләреннән белешмә (спорт, музыка, сәнгать мәктәпләре, секцияләр, түгәрәкләр, курслар һ. б.)*

*- ата-аналар паспортының күчермәләре,*

*- ата-аналарның эш урыныннан белешмә.*

«___» _____________ 20___ ел                    Имза ___________